| | |
|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ<br>РАЙОННЫЙ СОВЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 марта 2021 г. № 44

**Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт кәгазе) бирү Тәртибен раслау турында**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2021 елның 16 гыйнварындагы 11/13-09/119 номерлы хатын үтәү йөзеннән һәм Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт кәгазе) бирү тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлеге башлыгына йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин

Татарстан Республикасы
Балтач район Советының
2021 елның 15 март
44 номерлы карарына
кушымта

**Җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт кәгазе) бирү тәртибе**

1. «Исемлек буенча җир эшләренең барлык төрләрен (1 нче кушымта) башкару бары тик җир эшләрен башкаруга ордер булганда гына рөхсәт ителә (алга таба - Ордер).

Шәһәр территориясен төзекләндерүгә, җир эшләрен башкаруга ордер рәсмиләштерүгә һәм алуга бәйле җир, төзелеш һәм ремонт эшләрен оештыру һәм уздыру тәртибе үзидарә органнары хокукый актларының билгеләнгән таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла».

2. Төзелеш һәм җир эшләрен, территорияне төзекләндерү белән бәйле инженерлык коммуникацияләрен төзү һәм ремонтлау эшләрен башкару вакытларын килештерү һәм координацияләүне вәкаләтле орган башкара. Җир эшләрен башкаруга ордер вәкаләтле орган тарафыннан бирелә.

3. Җир эшләрен башкаруга ордер алу өчен Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлегенә (алга таба - Вәкаләтле орган), күпфункцияле үзәккә мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ордер алу бурычы заказ бирүчегә яки эш башкаручыга йөкләнә.

Эшне башкаручы, заказ бирүченең рәсмиләштерелгән ордеры булуына инанмыйча, эшләр башкарырга хокуклы түгел.

Вәкаләтле орган җир эшләрен башкаруга ордер алуга язма гариза алганнан соң 10 көн эчендә түбәндәгеләрне эшли:

а) документларның булу-булмавын һәм аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерү үткәрә;

б) проектның дәүләт шәһәр төзелеше нормативлары һәм кагыйдәләре таләпләренә туры килүен тикшерү үткәрә;

в) җир эшләрен башкаруга ордер бирә яки баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, ордер бирүдән баш тарта.

Вәкаләтле орган түбәндәге очракларда ордер бирүдән баш тарта:

- проектның шәһәр төзелеше нормативларына туры килмәгәндә,

- Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булганда.

4. Җир эшләрен башкаруга Ордер капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау буенча оешманың, предприятиенең, учреждениенең вазыйфаи затына, физик затка - заказ бирүчегә бирелә.

5. Җир эшләрен башкаруга ордер биргәндә вәкаләтле орган, җирле шартларны исәпкә алып, эшләрне башкару вакытларын һәм бозылган төзекләндерүне тулысынча торгызу вакытларын билгели.

Ордер, гамәлдәге төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре белән каралган эшләрне башкаруның норматив дәвамлылыгын исәпкә алып, эшләрне башкаруның билгеләнгән графигы нигезендә, билгеләнгән вакытка рәсмиләштерелә.

Ордер анда күрсәтелгән төр, күләм, вакыт һәм урын өчен гамәлдә. Эшләр ордерда күрсәтелгән эш башкаручы тарафыннан гына башкарыла ала. Эшләрне башкару барышында гариза бирүче вәкаләтле органга рөхсәт кәгазен бирү шартларын үзгәртү (җаваплы эш башкаручы, лицензияләр вакыты тәмамлану, проект карарларының мөһим үзгәрешләре һ. б.) турында хәбәр итә. Ордерда күрсәтелгән эш башкаручы алышынган, объектны башка эш башкаручыга тапшырган очракта, ордер бирелгән эшләрнең заказ бирүчесе аны кичекмәстән башка эш башкаручыга яңадан рәсмиләштерергә тиеш. Гамәлдәге ордерга үзгәрешләр һәм өстәмәләр аны бирү урыны буенча гына кертелә.

Ордерда күрсәтелгән эшләрне башлау вакыты 5 (биш) көнгә тоткарланганда, эшләр башкаруга бирелгән ордер гамәлдә түгел дип таныла һәм вәкаләтле органга вакыты чыкканнан соң 3 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

6. Төзелеш дәвамлылыгы бер айдан артык булган эшләр башкарганда, җир эшләрен башкаруга ордер аерым этапларга, аларның һәркайсына эш вакытын билгеләп, бирелергә мөмкин.

7. Әгәр элек башкарылган җир эшләре буенча эш башкаручының яки заказ бирүченең әлеге Кагыйдәләрнең нигезләмәләрен системалы рәвештә (2 һәм аннан да күбрәк тапкыр) үтәмәве, эш башкаручы яки заказ бирүче тарафыннан җир эшләрен башкаруның килештерелгән вакытларын системалы рәвештә бозулар (2 һәм аннан да күбрәк тапкыр) булуы, төзекләндерү торгызылмавы яки башланган эшләр тәмамланганчы һәм аларны үтәгәндә җибәрелгән хокук бозулар бетерелгәнче ордер буенча нинди дә булса бурычлар булуы ачыкланса, Вәкаләтле орган ордер бирүдән баш тарта.

8. Вәкаләтле орган ордерның гамәлен түбәндәге очракларда туктатып тора:

- ачыкланган хокук бозуларны бетерү буенча күрсәтмәләрне эш башкаручы тарафыннан системалы рәвештә (2 һәм аннан да күбрәк) үтәмәү;

- әгәр җир эшләре башкарыла торган объектның торышы кешеләрнең тормышына, сәламәтлегенә һәм транспорт хәрәкәтенә куркыныч тудырса;

- заказ бирүче яки эш башкаручы тарафыннан ордерны рәсмиләштерүнең билгеләнгән тәртибен бозуларны ачыклау, аны биргәндә

нигез булган рөхсәт кәгазьләренең, килештерүләрнең гамәлләрен вакытлыча туктату;

- җир эшләре алып барыла торган урын белән янәшә урнашкан биналарның һәм корылмаларның конструкцияләре һәм элементлары деформациясе барлыкка килү.

Ордерның гамәлдә булуы туктатылган очракта, эш башкаручының ордеры тартып алынырга тиеш, алмашка бозуларны бетергәнче, эшләрне туктатуга күрсәтмә бирелә.

Ордерның гамәлдә булуын туктатып торуга сәбәп булган бозуларны бетергәннән соң, аны кабат гамәлгә кертәләр (ордер эш башкаручыга кире кайта). Шул ук вакытта ордерда аның гамәлдә булуын тиешле чорда туктатып тору турында билге ясала.

Ордерны кабат гамәлгә кертү хокук бозуларны бетерүне раслаучы һәм җир эшләрен башкарганда әлеге Кагыйдәләрне үтәүне гарантияләүче эш башкаручының Вәкаләтле органга язмача мөрәҗәгате буенча башкарыла.

9. Вакыты узган ордер буенча эшләрне гамәлгә ашыру тыела. Вакыты узган ордер буенча эшләр башкару җир эшләрен рөхсәтсез башкару дип таныла. Эшләрне билгеләнгән вакытка үтәлмәгәндә яки эшләрне ордерда билгеләнгән вакытка тәмамларга мөмкинлек бирми торган сәбәпләр килеп чыккан очракта, заказ бирүче яки эш башкаручы эшләрне башкару вакытын озайту турында язма үтенеч белән Вәкаләтле органга мөрәҗәгать итәргә тиеш. Озайту ордерда күрсәтелгән эшләрне тәмамлау вакыты чыкканчы биш календарь көннән дә ким булмаган вакыт эчендә башкарыла.

10. Финанслау булмау сәбәпле, эшләрне туктатканда, эшләрне башкару хокукыннан башка (бары тик төзелеш мәйданчыгының киртәсен һәм территориясен карап тоту өчен генә), төзелеш мәйданчыгын карап тоту өчен тулы җаваплылык белән, ордер эшкә заказ бирүчегә үзгәртеп рәсмиләштерелә.

Озак вакытлар финансланмаган очракта объектның эше туктатылып торырга (консерваланырга), ордер ябылырга мөмкин. Эше туктатылган (консерваланган) объектны карап тоту өчен заказ бирүче җаваплы.

11. Зур озынлыктагы трассаларда һәм автомобиль юллары кисешкән вакытта, Ордер аерым участокларга, суүткәргечкә, канализациягә, җылылык трассасына, газүткәргечкә 100 м.оз. артмаган һәм телефонга һәм электр кабельләренә 200 м.оз. артмаган һәм автоюллар киселешенә аерым, һәр участокка эшләр вакытын билгеләп бирелә.

12. Әгәр территория түбәндәге хәлдә булса, әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән очракларда ордерларны рәсмиләштерүнең гамәлдәге тәртибе үзгәрә:

- хәрби хәлдә;
- гадәттән тыш хәл режимында;
- террорчылыкка каршы операция үткәрү зонасында;

- табигый бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү зонасында һ. б.;

- авария очраклары зонасында.

13. Инженерлык челтәрләрендә аварияләрне бетерелгәндә, эшләрне башкаруга ордерны алдан рәсмиләштермичә (авария турындагы телефонограмма буенча), аны бер тәүлек эчендә рәсмиләштерү шарты белән авария хезмәтләре тарафыннан казу эшләрен алып бару рөхсәт ителә.

Бу очракта ордер биргәндә, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булуы исәпкә алынмый.

14. Казу эшләре башланганчы, авария бригадасын җибәрү белән бер үк вакытта эксплуатацияләү оешмасы эшләрне уздыру урыны, җаваплы затларның шәхси мәгълүматлары турында вәкаләтле органга хәбәр итәргә, шулай ук инженерлык корылмаларын эксплуатацияләүче оешмаларга, РФ Эчке эшләр министрлыгы бүлегенә (юлларны чикләү яисә ябу кирәк булганда) авария турында телефонограмма аша хәбәр итәргә, яшелләндерү территориясендә авария эшләрен уздырганда вәкаләтле органга хәбәр итәргә.

1 нче кушымта

Эшен башкаруны башлар алдыннан ордер алырга кирәк булган эшләр исемлеге

1. Төзелеш, реконструкция һәм капиталь ремонт.

1.1. Җир асты инженерлык челтәрләре:

- торба үткәргечләр, суүткәргечләр, канализация, җылылык челтәрләре, нефть үткәргечләр һәм газүткәргечләр, яңгыр канализациясе, дренаж;

- кабельле, электр челтәрләре, элемтә челтәрләре, радио, телевидение, светофорлар, урам утлары.

1.2. Юллар, урамнарның машиналар йөрү өлеше, тротуарлар, ян-яктагы (борт) таш, бүлү полосалары, терәү стенкалары, газоннар, электр линияләре терәүләре, тышкы реклама чаралары, светофорлар, яктыртыла торган юл билгеләре, мәгълүмат күрсәткечләре.

1.3. Торак, административ һәм җитештерү биналары.

1.4. Биналар (аерым торучы, янәшә төзелгән), вакытлы җир өсте корылмалары:

- сәүдә, җәмәгать туклануы, көнкүреш хезмәте күрсәтү объектлары, автосервис, автозаправка станцияләре, ачык машина кую урыннары һ.б. (аларның киртәләрен дә кертеп).

2. Биналарда, беренче катлардагы корылмаларда урнашкан һәм гомуми файдаланудагы территориягә тышкы чыгу юлы булган торак булмаган биналарны реконструкцияләү, яңадан җиһазлау, яңадан планлаштыру һәм капиталь ремонтлау.

3. Котлованнарны ачу һәм биналарның һәм корылмаларның, шул исәптән гаражларның фундаменты астына субай сугу, карьерлар эшләү (туфракны проектка кадәр эшләп чыгару һәм төзелеш материалларын табу).

4. Биналарны һәм корылмаларны сүтү, инженерлык коммуникацияләрен чыгару (бетерү).

5. Биналарны һәм корылмаларны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау яки сүтү вакытында төзелеш мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу.

6. Территорияләрне вакытлы һәм стационар коймалар белән әйләндереп алу.

7. Бораулау:

7.1. Инженер-геологик скважиналар.

7.2. Гидрологик скважиналар.

7.3. Су астына скважиналар һ. б.

7.4. Кагылма һәм тамырсыман субайлар.

8. Шурфларны ачу.

9. Фундамент нигезләрен ныгыту.

10. Фильтрлауга каршы эшләр.

11. Территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерү.

12. Планлаштыру эшләре (туфракны кубару һәм читкә өю, иңкүлекләрне һәм чокырларны күмү).